# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге составына керүче Ак-Юл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«15» декабрь 2021 ел № 4

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2021 елның 15 декабрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-тамак авыл җирлеге составына керүче Ак-Юл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән , көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I һәм II төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

-Ак-Юл торак пунктында Лесная урамы буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (төзелеш, реконструкция, ремонт, вак таш салу, җәю, ташу, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 18 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 16 кеше катнашты, бу 88,9% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда 16 кеше тавыш бирде;
- «ЮК» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлегенең Ак-Юл торак пунктында халык җыенын узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлегенә керүче Ак-Юл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I һәм II төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Федерациясенең Кораллы көч сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?:

-Ак-Юл торак пунктында Лесная урамы буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (төзелеш, реконструкция, ремонт, вак таш салу, җәю, ташу, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Дим-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга мөмкин: http://jutaza.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы,
Ютазы муниципаль районы
Дим-Тамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов